ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 195-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы — М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 665-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш); 2026, № 1 (I өлеш), «2026 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2031 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында аның 2026 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән махсус инвестиция контрактларында катнашучы салым түләүчеләргә карата кулланылуы билгеләнә.

«Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль законның $18^2$ статьясындагы 2 өлеше нигезендә махсус инвестиция контрактлары 2030 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча төзелә.

Шуңа бәйле рәвештә, шулай ук Татарстан Республикасына инвесторлар җәлеп итүгә кызыксындыру, инвестицион җәлеп итүчәнлекне арттыру һәм сәнәгать җитештерүен үстерү максатларында закон проектында ташламалы шартларның гамәлдә булу вакытын озайту – 2031 елның 1 гыйнварына кадәр төзелгән махсус инвестиция контрактларында катнашучыларга карата күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен куллану карала.

**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар таләп итми.

Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмаларга карата оешмалар табышына салым буенча ташлама суммасы 2026 – 2040 еллар (15 ел) чоры өчен алдан бәяләү буенча 1,4 млрд сумны тәшкил итәргә мөмкин.